Совет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1021606556850 ИНН 1617000612

==================================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

28 октябрь 2019 года № 51/2

## Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында

2019 нчы елның 26 июлендәге 226-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә нотариат турындагы законнар нигезенә һәм "Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 16_1 статьясына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 37 статьясында каралган нотариаль гамәлләр кылу хокукына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегенең түбәндәге вазыйфаи затлары ия:

Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы һәм (яисә) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтле вәкиле.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты секретарен тиешле авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр башкаруга вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге җирле үзидарәсенең әлеге карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән вазыйфаи затлары Иске Чокалы авыл җирлегендә, торак пунктта яшәү урыны яки тору урыны буенча теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:

1) күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен расларга;
2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән Мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;
3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын раслау;
4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләү;
5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклыйлар;
6) гражданның исән булу фактын таныклыйлар;
7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз имзасының, үз кулы белән куелган имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген расларга.;
8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклыйлар;
9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклыйлар;
10) документлар тапшыру вакытын таныклыйлар;
11) электрон документның кәгазьдә урнаштырылган документ белән тәңгәллеген раслыйлар;
12) кәгазьдәге документның электрон документка тәңгәллеген таныклыйлар.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 2008 елның 14 гыйнварында кабул ителгән 30 санлы «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында»гы карарлны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов